КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1144

Җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^4$ һәм $44^5$ статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.
3. Бу карарның гамәле, 2022 елга, 2023 һәм 2024 елларның план чорына бюджеттан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 27 ноябрь, 1144 нче
карары белән расланды

Җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрү тәртибе

1. Бу Тәртип җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының (алга таба – резерв фонды) бюджет ассигнованиеләрен арттыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү турында килешү төзелмәгән субсидия (башка бюджетара трансферт) күләмендә җибәрү механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^4$ һәм $44^5$ статьялары нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр төзүне тәэмин итүче Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр агымдагы финанс елының 20 февраленә кадәр (агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән 36 нчы көннән дә соңга калмыйча) төзелгән килешүләр реестрларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертә.

3. Агымдагы финанс елның 15 февраленә (агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән 30 нчы көнгә) кадәр төзелгән килешү булмаган очракта, Татарстан Республикасы бюджетының җирле бюджетларга субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүгә, агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчегә каралган бюджет ассигнованиеләре Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегенә бирелә торган субсидия (башка бюджетара трансферт) күләменә тигез күләмдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү турында килешү төзелмәгән субсидия (башка бюджетара трансферт) күләмендә җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү өчен резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы:

а) агымдагы финанс елының 1 мартына кадәр (агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән 40 нчы көнгә) агымдагы финанс елында резерв фондын арттыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

б) резерв фондын арттыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы үз көченә кергән көннән агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертә.

5. Резерв фондының бюджет ассигнованиеләре бу Тәртипнең 3 пункты нигезендә резерв фондына җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре (алга таба – резерв фондының бюджет ассигнованиеләре) күләме чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә аларны бирү өчен элек билгеләнгән максатларга туры килә торган максатлар өчен җирле бюджетларга субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирүгә файдаланыла.

6. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр агымдагы финанс елының 15 мартына кадәр элек билгеләнгән максатларга туры килә торган максатлар өчен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләренә субсидия (башка бюджетара трансферт) бирү өчен резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тәкъдимнәр кертә.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдимнәр, резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары проектларын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бүленешенең исәп-хисапларын теркәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертелә.

7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бу Тәртипнең 6 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдимнәр нигезендә агымдагы финанс елның 1 апреленә кадәр, резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары проектларын теркәп, субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) исемнәрен, аларны бирү максатларын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасындагы бүленешен күрсәтеп, агымдагы финанс елында җирле бюджетларга субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гомумиләштерелгән тәкъдимнәр кертә.

8. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган җирле бюджетларга субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары нигезендә җирле бюджетларга субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү өчен резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр, тиешле хисап чоры өчен квартал (еллык) бюджет хисаплылыгын бирү өчен билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формада финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган җирле бюджетларга субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) бирү турындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрә.

---